Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы

**КАРАР №6**

Рус Әшнәге авылы 2020 елның 15 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 маддәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 19,86,87,88 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 апрелендәге VI-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының 01.12.2016 ел 50, 25.07.2017 ел 6, 27.04.2018 ел 5 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итәргә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль

законның 44 маддәсенең 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Уставының 88 маддәсенең 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы В.Х.Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәге авыл
җирлеге Советының
2020 елның 15 октябрендәге
6 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

5 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

“Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән (рөхсәтсез) төзелгән корылманы сүтү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү”;

2) 6 маддәнең 1 пунктындагы 13 пунктчасында “яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм асрау чаралары”сүзләрен “яшәүче, иясез хайваннар белән мөгамәлә итү эшчәнлеге” сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:

“16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазыйфаны биләве чорында торак урыны бирү.”;

4) 22 маддәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсендә каралган гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы (вәкаләтле). Торак пунктта бер үк вакытта әлеге торак пункттагы сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең

яртысыннан артыгының бергә җыелу (булу) мөмкинлеге булмаса, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены этаплап, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә үткәрелә. Шул ук вакытта гражданнар җыенында элегрәк катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы яклап тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.”;

5) 23 маддәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

“3. инициатив проектны тормышка ашыру тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегендә яки аның бер өлешендәге уналты яшькә җиткән яшәүчеләрне (-ң) – бу инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.”;

6) 23 маддәнең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Гражданнардан сораштыруны билгеләү турында карар җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Җирлек Советының гражданнардан сораштыруны билгеләү турындагы карарында түбәндәгеләр тәгаенләнә:

1) сораштыруны уздыру датасы һәм сроклары;

2)сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган сорауның (сорауларның) формулировкасы (тәгъбирләнеше);

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең рәвеше;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

6)“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү (таныклау) тәртибе;.

7) 30 маддәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Җирлек Советы депутаты “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Совет депутаты вәкаләтләре “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, наличный акча средстволары һәм хәзинәләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, йөкләмәләрне (вазыйфаларны) башкармау очрагында, әгәр башкасы 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми

принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законда күздә тотылмаган булса, вакытыннан алда туктатыла;”;

8) 30 маддәнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8. Әлеге маддәнең 7 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, наличный акча средстволары һәм хәзинәләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, йөкләмәләрне (вазифаларны) үтәмәү фактлары ачыклаганда, Татарстан Республикасы Президенты депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә күрсәтелгән затка карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка башка җаваплылык чараларын куллану турындагы гариза (белдерү) белән мөрәҗәгать итә.”;

9) 30 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 9.1, 9.2 пунктларын өстәргә:

“9.1. Үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшырган җирле үзидарә депутатына, әгәр әлеге мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органындагы вазыйфасыннан азат итү;

3) вәкаләтләр вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазифалар биләүдән тыю;

5) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.”;

9.2. Депутатка карата әлеге маддәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә үзидарәлек хокукый акты белән тәгаенләнә.”;

10) 43 маддәнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Җирлек башлыгы 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүчеләрнең һәм бүтән затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе

территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, наличный акча средстволары һәм хәзинәләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, йөкләмәләрне (вазыйфаларны, бурычларны) башкарырга тиеш;

8) 33 маддәнең 1 пункты 24 пунктчасын, 49 маддәнең 1 пункты 3 пунктчасының 7 абзацын көчен югалткан дип таныырга;

9) 49 маддәнең 1 пункты 7 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга :

"Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү (сүтү) яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү";

11) 49 маддәнең 2 пунктының 13 абзацында "даими яшәүче караучысыз хайваннарны тотып алу һәм асрау буенча чараларның" сүзләрен "даими яшәүче иясез хайваннар белән мөгамәлә (эш) итү буенча эшчәнлекнең" сүзләре белән алмаштырырга;

12) 57 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләмәүче затка әлеге маддәнең 2 өлешендәге 1 - 4 һәм 10 пунктларында каралган гарантияләр бирелә, муниципаль вазыйфа биләүгә бәйле чыгымнарны, шул исәптән муниципаль вазыйфа биләүгә бәйле рәвештә хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә компенсацияләү, шулай ук дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә торган чорга эш урынын (вазыйфаларын) саклап калу гарантияләнә һәм ул тулаем алганда аена икедән ким һәм алты эш көненнән артык була алмый.".

13) 63 маддәдә:

а) 1 пунктның 2 пунктчасында "әгәр федераль законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктларны өстәргә:

"6. Үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшырган җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата, әгәр әлеге мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы җирле үзидарәнең сайланулы органында вазифалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазифасыннан азат итү;

3) вәкаләтләр вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы җирле үзидарәнең сайланулы органында вазифалар биләүдән тыю;

5) вәкаләтләре вакыты туктатылганга чаклы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.”;

“7. Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә үзидарәлек хокукый акты белән тәгаенләнә.”;

14) 85 маддәнең 1 пунктында “Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм башка норматив” сүзләрен "нигезләмәләрнең" сүзе белән алмаштырырга, ",ачык норматив йөкләмәләрне һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга бүтән түләүләр буенча йөкләмәләрне шарт белән чикләүче хокукый актларның, шулай ук бюджеттан средстволар бирү турында дәүләт (үзидарәлек) контрактларының, шартнамәләренең (килешүләренең) шартларын үтәүнең” сүзләре белән тулыландырырга;

15) 85 маддәнең 2 пунктында “бюджет хокукый мөнәсәбәтләре өлкәсендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

16) 85 маддәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Эчке үзидарәлек финанс контроле җирлек Башкарма комитеты органнары (вазыйфаи затлары) булган үзидарәлек финанс контроле органнарының контроль эшчәнлеге булып тора.”;

17) 2021 елның 1 гыйнварына кадәр 79 маддәнең 3 өлешенең, 84 маддәнең 5 өлешенең гамәлдә булуын туктатып торырга (туктатырга).

18) 88 маддәнең 2 пунктының беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Җирлек Уставы (Низамнамәсе), әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек Советы карары аларны дәүләт теркәвеннән соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының “Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары”порталында рәсми төстә игълан ителергә (халыкка белдерелергә) тиеш (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф, челтәр басма сыйфатында теркәлү: Эл № ФС77-72471 05.03.2018)”.